**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 , РТ, Лаишевский район, село Атабаево, ул.Молодежная, д.1
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422635,РТ, Лаеш районы, Атабай авылы , Яшьлэр урамы, 1 нче йорт,
тел: 8-(84378) -4-87-41
факс: 8-(84378) -4-87-41

---

**№8** **2019 елның 15 апреленнән**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджетыннан алынучы башка бюджетара трансфертлар исәбенә башкарылучы чыгымнар юнәлешен раслау турында**

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсүен стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 12 апреленнән №840 “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджетыннанТатарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанс тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар тәкъдим итү Тәртибен раслау турында”гы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2003 елның 6 октябреннән №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 14 маддәсенә ярашлы төстә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджетыннан алынучы башка бюджетара трансфертлар исәбенә башкарылучы чыгымнар юнәлешен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Лаеш муниципаль районы**
**Атабай авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Л.Р.Хәлилова**